**III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XLIV СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р №187**

Мөслим «17» июнь 2020 ел

**Аренда түләүләреннән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 670-р номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында, аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында»гы 434 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» карары белән расланган иң күп зыян күргән, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгате көненнән алып 7 эш көне дәвамында, 2020 елның апрель-июнь айларында муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча арендачыларны аренда түләүләреннән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзергә. Аренда түләүләреннән азат итү - аренда килешүендә күрсәтелгән төрне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру максатларында муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булса һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булган очракларда гамәлгә ашырыла;

б) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында арендага алучылар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштырырга.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләреннән азат итү - Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл

режимы кертелгән датага, аларның муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре буенча йөкләнгән бурычы булмаган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән, әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыручы арендачыларга - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына карата гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениясенә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында https://muslumovo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль
районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы
Советы рәисе Р.Х. Муллин